Республика Татарстан
Глава Верхне-Чершилинского
сельского поселения
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Югары Чыршылы авыл
җирлеге башлыгы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.03.2024 № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №2, «Югары Чыршылы торак пунктында гражданнарның 2024 елда үзара салым кертү турында»17.11.2023 №1 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1.2024 елның 29 мартында 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Югары Чыршылы авылы, Ленин урамы, 40 а йорт адресы буенча урнашкан Югары Чыршылы авыл мәдәният йорты бинасында "Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында»17.11.2023 №2 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында» 17.11.2023 №2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы?

1) Югары Чыршылы торак пунктында ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (мәгълүмат стендларын сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Югары Чыршылы торак пунктында жир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү, чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары, вак ташлар сатып алу, мәгълүмати стендлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү)

3) Югары Чыршылы торак пункты территориясен төзекләндерү (махсуслаштырылган техникага - МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу); Югары Чыршылы торак пунктында балалар мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, мәгълүмати стендлар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү)

4) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Югары Чыршылы торак пунктында кышкы вакытта юлларны кардан чистарту);

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Югары Чыршылы торак пунктында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү).

«ӘЙЕ «ЮК»

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдинов